МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

# ПРИКАЗ БОЕРЫК

07.06.2022 № 325-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 26 мартындагы 187-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчегә аттестация уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны федераль законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчегә аттестация уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2019 елның 26 мартындагы 187-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы дәүләт белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга һәм җитәкчегә аттестация уздыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын, белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларын раслау турында» 2013 елның 8 августындагы 678 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын, белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларын раслау турында» 2022 елның 21 февралендәге 225 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсе күчермәсе яисә хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;»;

4.12 пунктта «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе җитәкчесенең эшчәнлек күрсәткечләре исемлеген, аның эшенең нәтиҗәлеген бәяләү критерияләрен һәм аны премияләү тәртибен раслау

турында» 2012 елның 10 июлендәге 342-осн номерлы боерыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Лубян урман-техник көллияте» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе директоры хезмәтенә түләү турында» 2019 елның 16 апрелендәге 336-осн номерлы боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

4.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Белем бирү учреждениесе җитәкчесе аттестация комиссиясе утырышында шәхсән үзе яисә, видеоконференц-элемтә чараларын кулланып, дистанцион формада катнашырга тиеш.»;

1 нче кушымтада, «Хезмәт кенәгәсеннән өземтә» сүзләреннән соң, «яисә хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

3 нче кушымтаның 2.6 пунктында «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Лубян урман хуҗалыгы техникумы» урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе җитәкчесенең эшчәнлек күрсәткечләре исемлеген, аның эшенең нәтиҗәлеген бәяләү критерияләрен һәм аны премияләү тәртибен раслау турында» 2012 елның 10 июлендәге 342-осн номерлы боерыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Лубян урман-техник көллияте» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе директоры хезмәтенә түләү турында» 2019 елның 16 апрелендәге 336-осн номерлы боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (В.В.Мәнихова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров